ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18 март, 2021 ел № 6/6

Шәһәр Советының 2016 елның 7 апрелендәге 7/17 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, аларның гаилә әгъзалары тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрне шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына рәсми бастыруга бирү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында «Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указы, Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре» 2013 елның 8 июлендәге 613 номерлы Указы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2016 елның 7 апрелендәге 7/17 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, аларның гаилә әгъзалары тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрне шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына рәсми бастыруга бирү Тәртибенә (Шәһәр Советының 2018 елның 21 февралендәге 23/12 номерлы Карары редакциясендә), 2 өлешнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«4) җир участогын, күчемсез мөлкәтнең башка объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу, пайлар өлешен), цифрлы финанс активларын, цифрлы валюта сатып алу буенча

алыш-бирешләр (алыш-биреш) башкару өчен тотылган акчаларның гомуми суммасы хезмәткәрнең һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, соңгы өч елда алынган керем чыганаклары турында белешмәләр.»

2. Әлеге Карарның гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварыннан соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ